ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 28 апреле**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1169**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2016-2017 елның ягып җылыту чоры тәмамлану турында

2005 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 17 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы нормативтан югарырак(+8°С) булу сәбәпле, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җылылык энергиясен төрле билгеләнештәге биналарны җылытуга җибәрүче предприятие һәм оешмалар җитәкчеләренә 2017 елның 28 апреленнән Зеленодольск муниципаль районы территориясендә ягып җылыту чорын тәмамларга тәкъдим итәргә.
2. Тышкы һава температурасы кискен төшкән очракта, җылылык буенча хезмәт күрсәтүче предприятиеләргә, биналар һәм торак биналар эчендә җылылык белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтүче инженерлык челтәрләренә җылылык җибәрүне күздә тотарга.
3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo. tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче А.Х.Сәхибуллин